

2025 елнын 5 декабрендә Идел буе федераль округы Закон чыгаручылар советы утырышы Казанда узды. Идел буе закон чыгаручылары жирле vзидарәнен хокукый нигезләре һәм эчке туризмны vстерv турында фикер алыштылар. Чарада Россия Федерациясе Президентынын Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров; Татарстан Республикасы Рәисе Ростәм Миннеханов; Идел буе федераль округы Закон чыгаручылар советы рәисе, Тvбән Новгород олкәсе Закон чыгару Собраниесе рәисе Евгений Люлин; Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы Рәисе урынбасары Константин Косачев, шулай ук округ тобәкләренен закон чыгару һәм башкарма хакимият вәкилләре, Идел буе федераль округынын Яшьләр парламентлары әгъзалары катнашты. Мордовиядән - республика Дәvләт Жыены - Госсобрание житәкчесе Владимир Чибиркин һәм Яшьләр парламенты рәисе Виктория Богдашкина.
Утырыш барышында Игорь Комаров билгеләп vткәнчә, Идел буе федераль округында яшәvчеләрнен яртысына якыны жирле хакимият эшен унай бәяли. Идарә итv алымнарын камилләштерv очен шактый резервлар жирле vзидарәне оештыру системасында 2025 елнын 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон белән беркетелгән vзгәрешләр нәтижәсендә барлыкка килгән. Яналыклар жирле vзидарәнен бер дәрәжәле моделен куллануны кинәйтә. Шул ук вакытта идарә итvнен нәтижәлелеген һәм комплекслылыгын тәэмин итv очен кирәк булган ике дәрәжәле модель саклана. Мондый сыгылмалы якын килv функцияләрне кабатлауны киметергә, халык һәм бизнес мәнфәгатьләрендә карарлар кабул итvне тизләтергә момкинлек бирә. Кире элемтәнен сыйфатын яхшырту очен карарлар кабул итv процессында гражданнарнын катнашу форматлары (жыеннар, сораштырулар, тынлаулар, инициатив проектлар һ.б.) янартылды.
Яна законнар кысаларында округ тобәкләрендә идарә итvнен заманча системаларына кvчv буенча актив эш алып барыла. Идел буе федераль округы Закон чыгаручылар советы рәисе Евгений Люлин ассызыклаганча, янартылган законнар тобәк vзенчә-лекләреннән чыгып, жирле vзидарә моделен сайлау хокукын бирде. Бvген муниципаль һәм тобәк хакимиятләре арасында вәкаләтләрне янадан бvлv бурычы тора.
Икенче мәсьәлә буенча Игорь Комаров билгеләп vткәнчә, туризм– тобәкләр тормышынын двигателе, бу хакта Президент Владимир Путин берничә тапкыр әйтте. Әйтик, 3 ел эчендә Идел буе федераль округында туристлар агымы 25% ка арткан (РФдә - 19,6% булганда). 2025 елнын 9 аенда бу 16 млн. сәфәр. Вәкаләтле вәкил шулай ук проблемаларга игътибар итте.
- Хәзер округ икътисадында туризм Россия буенча 2,9% булганда тулаем тобәк продуктынын 2,2% алып тора. Топ кыенлыклар – бюрократия, инфраструктура житмәv, мәсәлән, ерак районнарда кунакханәләр, профессиональ кадрлар житмәv, сезонлылык. Бу факторларны бетерv очен законнар базасы, урыннарда vтә кvренмәле идарә булырга тиеш. Региональ дәрәжәдә, һәр территориянен vзенчәлекләрен исәпкә алып, остәмә чаралар эшләргә кирәк, - дип ассызыклады Игорь Комаров.
Ростәм Миннеханов vз чиратында билгеләп vткәнчә, уникаль мәдәни һәм табигый объектларны популярлаштыру һәм заманча инфраструктураны vстерv эчке туризмны

яна дәрәҗәгә чыгарырга момкинлек бирәчәк.
Утырыш барышында Мордовия Госсобрание житәкчесе Владимир Чибиркин Мордовиянен экологик туризмны vcтерv тәжрибәсе турында сойләде.
- Экотуризм - туган якны ойрәнv момкинлеге, табигатькә карата жаваплы, сакчыл монәсәбәт тәрбияләv, аз кеше яшәгән территорияләрдә эш урыннарын саклау, финанс һәм салым керемнәре чыганагы ул. Һәм ахыр чиктә - бу регионнарнын тотрыклы vсеше очен корал, - дип ассызыклады Владимир Чибиркин.
Мордовиядә 100 махсус саклаyчы табигый территория (3 федераль, 87 тобәк һәм 10 жирле әһәмияттәге), шул исәптән милли парк һәм табигать тыюлыгы урнашкан.
Саранскида экотуризмнын берничә объекты урнашкан. Алар арасында имәннәр музее һәм ботаника бакчасы бар. «Кречет» Сафари-паркы, «Ашо лисьма» эко-паркы кебек шәхси экотуризм мәйданчыклары актив vсә.
- Экотуризмны vcтерv-озак сроклы стратегик бурыч. Без Мордовиянен кунаклар очен ачык һәм vз мирасына сакчыл караган тобәк буларак актив vсешен дәвам итvен телибез, – дип нәтижә ясады Идел буе федераль округы Закон чыгаручылар Советындагы чыгышына Владимир Чибиркин.
Сенатор Константин Косачев фикер алышу барышында туристларны жәлеп итv очен ресурсларны берләштерергә һәм Тобәкара проектлар булдырырга кинәш итте. Идел буе федераль округы Закон чыгаручылар советынын эш коне кысаларында анда катнашучыларга #МУЗЫКАВМЕСТЕ – «Боек ил жыр-лары» (#МУЗЫКАВМЕСТЕ – «Песни Великой Страны. С любовью из Приволжья») проекты тәкъдим ителде. Әлеге проект Россия Президентынын Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров, Президентнын Мәдәни инициативалар фонды һәм «Россия ДНКсы» проекты ярдәмендә гамәлгә ашырыла.
Әйтеп китәргә кирәк, #МУЗЫ-КАВМЕСТЕ командасы Идел буе федераль округынын 14 тобәгендә булган. Проектта 400дән артык солист һәм ижат коллективы катнашкан. Барлыгы жиде музыка тарихы чыгару планлаштырыла. Инде алты видеоклип тәкъдим ителгән: «Течет река Волга», «Гляжу в озера синие», «Как молоды мы были», «Вместе весело шагать», «Наш сосед» һәм «Так случилось, мужчины ушли».

*Наилэ НАСЫРОВА эзерлэде*